ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Җитәкче булып эшләүче муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында муниципаль берәмлекнең әлеге җирле үзидарә органының, сайлау комиссиясе аппаратының сайланулы һөнәр берлеге органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатен кайгырта алмый.»;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында:

«сәяси партия белән идарә итүдә катнашу;» сүзләреннән соң «түләүсез нигездә һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу;» сүзләрен өстәргә;

«бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«сәяси партияләрдән» сүзләреннән соң «һәм һөнәр берлеге органыннан, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе

аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацы 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ 106-ТРЗ